**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы**
**Сөендек авыл җирлегенең Сөендек торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**12 ноябрь 2019 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Сөендек авыл җирлегенең Сөендек торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Сөендек авыл җирлегенең Сөендек торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, I төркем инвалидлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүне гамәлгә ашырырга.

2. Аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Сөендек авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзекләндерү;
- Сөендек авылында һәлак булган сугышчыларга куелган обелискны төзекләндерү.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **Х.А. Измайлов**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Сөендек авыл җирлеге башлыгы** **Х.А. Измайлов**